**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 6 декабрь № 895

г. Казань

«Килдураз авылы республика балалар шифаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесен оештыру турында

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында «Автоном учреждениеләр турында» Федераль законны тормышка ашыру чаралары хакында» 2007 ел, 29 март, ПУ-155 нче Указы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләрен оештыру, үзгәртеп оештыру, аларның тибын үзгәртү һәм бетерү тәртибен билгеләү, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләрен гамәлгә куючы һәм аларның мөлкәте милекчесе функцияләрен һәм вәкаләтләрен регламентлаштыру өлешендә Татарстан Республикасында «Дәүләт (муниципаль) учреждениеләренең хокукый хәле камилләштерелүгә бәйле рәвештә, Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 ел, 8 май, ФЗ-83 нче Федераль законны тормышка ашыру чаралары хакында» 2010 ел, 18 октябрь, 820 нче карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының эшләп торучы «Килдураз авылы республика балалар шифаханәсе» дәүләт бюджет сәламәтлек саклау учреждениесе төрен үзгәртү юлы белән, учреждение эшчәнлегенең төп максатларын саклап, «Килдураз авылы республика балалар шифаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесен оештыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгын «Килдураз авылы республика балалар шифаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесен (алга таба – автоном учреждение ) гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкара торган Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы итеп билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына:

30 көн эчендә автоном учреждениенең уставын һәм күзәтү советы составын расларга;

ел саен автоном учреждение өчен аның уставында каралган төп эшчәнлек нигезендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен расларга;

20 көн эчендә автоном учреждениегә оператив идарә хокукында дәүләт мөлкәтен беркетү өчен кирәкле документларны, шул исәптән күчемсез мөлкәт объектларына техник документларны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына кертүне тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына билгеләнгән тәртиптә автоном учреждениенең уставын раслаганнан соң:

30 көн эчендә 422413, Буа муниципаль районы, Килдураз авылы, Гагарин урамы, 23 нче йорт адресы буенча урнашкан «Килдураз авылы республика балалар шифаханәсе» дәүләт бюджет сәламәтлек саклау учреждениесенә элек беркетелгән, автоном учреждение эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен, шул исәптән аеруча кыйммәтле мөлкәтне автоном учреждениегә оператив идарә хокукында беркетергә;

422413, Буа муниципаль районы, Килдураз авылы, Гагарин урамы, 23 нче йорт адресы буенча урнашкан автоном учреждениегә беркетелә торган күчемсез мөлкәт объектлары урнашкан җир кишәрлеген дүрт ай эчендә автоном учреждениегә даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында бирүне тәэмин итәргә.

5. Гамәлгә куючының дәүләт йөкләмәсен үтәвен финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1044 нче карарында билгеләнгән тәртиптә, тиешле финанс елына Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясе гражданнарына түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасында әлеге максатларга күздә тотылган акча чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\895.doc